# АГА ЧИШМӘ...

*ФИРЗӘР МОРТАЗИН музыкасы*
*СИБГАТ ХӘКИМ сүзләре*

Үзем су алам икән,
Үзем юанам икән.
Карыйм, карыйм, һич табалмыйм,
Нигә соң янам икән?

*Кушымта:*
Ага чишмә
Чылтыр-чылтыр,
Сөйли чишмә:
Ничек онытыр,
Ничек онытыр?..

Чишмәләр ага икән,
Юлларын таба икән.
Карыйм, карыйм, һич табалмыйм,
Күзләрем тала икән.

*Кушымта.*

Юлларга чыгам икән,
Уйларга чумам икән.
Карыйм, карыйм, һич табалмыйм.
Еракта томан икән.

*Кушымта.*